КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 21 ноябрь г.Казань № 1246

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында каты коммуналь калдыклар белән эш итү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында» 2017 ел, 6 июль, 460 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында каты коммуналь калдыклар белән эш итү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында каты коммуналь калдыклар белән эш итү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында» 2017 ел, 6 июль, 460 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 17 июль, 577 нче; 2018 ел, 13 декабрь, 1122 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1171, 2020 ел, 1 июнь, 453 нче; 2020 ел, 22 декабрь, 1174 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында каты коммуналь калдыклар белән эш итү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

ведомствоара эшче төркем составыннан Т.Т.Әһлиуллинны, Л.Ә.Гайнетдинованы, А.Ә.Кәримовны, Р.М.Карповны, Р.Р.Нигъмәтуллинны чыгарырга;

ведомствоара эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсенә караган юл һәм төзелеш комплексларында инвестиция программаларын тормышка ашыру бүлеге баш киңәшчесе Радик Рафаил улы Камаевны;

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры Олег Владимирович Коробченконы;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының калдыклар белән эш итү бүлеге төп консультанты Радик Раил улы Миңневәлиевны;

Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсе (Ростехнадзор) җитәкчесе урынбасары Азат Фәрид улы Мөбарәкшинны (килешү буенча);

«Альтернатив генерацияләү компаниясе –2» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры Олег Олегович Суздальцевны (килешү буенча);

Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) Фаяз Фәнил улы Шакировны.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин